ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 524 «09» 10 2025 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының «Дүртенче һәм аннан соңгы бала (балалар) туганда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2025 елның 25 июлендәге 376 номерлы карары белән расланган дүртенче һәм аннан соңгы бала (балалар) тапкан хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының «дүртенче һәм аннан соңгы бала (балалар) туганда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2025 елның 25 июлендәге 376 номерлы карары белән расланган дүртенче һәм аннан соңгы бала (балалар) тапкан хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле өченче абзац өстәргә:
"Дүртенче һәм аннан соңгы бала (балалар) туган ел дәвамында әлеге түләүне билгеләү турында гариза биргән гражданнар бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү алу хокукына ия. Декабрь аенда дүртенче һәм аннан соңгы бала (балалар) туган очракта, гражданнар мондый бала (балалар) туган көннән бала (балалар) туган елдан соң килүче елның 31 гыйнварына кадәр бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында гариза белән мөрәҗәгать итә алалар.»

1.2. Тәртипнең 5 пунктына «гариза биргән вакыттан» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru игълан итәргә

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

РТ Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы

В.А.Осокин